Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге составына керүче Каенлы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

# КАРАР

2022елның 18 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 18 ноябрендә уздырылган «Түбән Кама муниципаль районының Каенлыавыл җирлеге Каенлы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның ире/хатыннардан тыш; күрсәтелгән сумманың 50% күләмендә 2 группа инвалидлар һәм 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар түлиләр, 2023 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү белән килешәсезме:

– су челтәрләрен алыштыру (сатып алу, ташу, килешү буенча эш өчен түләү)

«ӘЙЕ» «ЮК».

мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 509 җыенда катнашучы граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан җыенда катнашучы гражданнар саны 261 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде: «Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 252 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 9 кеше тавыш бирде.

Бәянрителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге составына керүче Каенлы торак пунктында гражданнар җыенын булган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбән Кама муниципаль районының Каенлы авыл җирлеге Каенлы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның ире/хатыннардан тыш; күрсәтелгән сумманың 50% күләмендә 2 группа инвалидлар һәм 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар түлиләр,

2023 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү белән килешәсезме:

– су челтәрләрен алыштыру (сатып алу, ташу, килешү буенча эш өчен түләү)

«ӘЙЕ» «ЮК»

мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларына, Каенлы авыл җирлеге сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Каенлы авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Гарипов

«Совет Каенлинского сельского поселения Нижнекамского муниципального района Республики Татарстан»